

Россия журналистлары Союзы әгъзасы В.И.Ермишев Атюрьево районы мониторинг, анализ һәм прогноз бүлеге баш белгече Асия Шамиль кызы Бушара белән Россиядә, шул исәптән Мордовиянен Атюрьево районында халык исәбен алу ни рәвешле алып барылуы турында сөйләде.

- Асия Шамиль кызы, халык исәбен алу нәрсәгә кирәк?
- Халык санын алу, беренчедән, бу илдә булган халык исәбенен тогәл саны, анын составы турында, икенчедән, бу кешеләрнен тормыш шартлары, саны һәм составы үзгәрүне бәяләргә мөмкинлек бирә. Әлеге бәяләү ботен халыкка, шул исәптәп халыкнын санын алу үткән вакыт эчендәге үзгәрешләрне күзалларга ярдәм итә. Оченчедән, мондый үзгәрешләр динамикасы турындагы мәгълүмәт якындагы елларга халык саны үсеше перспективалары һәм социаль-икътисадый хәлгә топ билгеләмәләр очен нигез булып хезмәт итә.
Кеше санын алу ул - Россиянен елъязмасы, тарихы. Анын нәтижәләре безгә генә түгел, ә бездән сон яшәүчеләргә дә адресланган. Сан алу – гомуммилли туп- лануга, социаль киеренкелекне киметүгә ярдәм итүче акция. Аны үткәрү һәм нәтижәләре белән бар кеше кызыксына. Чонки ул – ботен илнен сәяси тормышында катнашунын бердәнбер реформасы.
- Халык санын исәпкә алу ничегрәк үтәр?
- Халык санын исәпкә алу сонгы тапкыр 2010 елнын 14-25 октябрендә узган иде. Ул вакытта Россиядә яшәүче 142,9 миллионлап кеше исәпкә алынды.
Исәпкә алу нәтижәләре буенча тулаем Россиядә, тобәкләрдә һәм муниципаль берәмлекләрдә халыкнын саны, милли һәм тел составы, белем дәрәҗәсе, социаль-икътисадый характеристикалары турында рәсми статистика мәгълүматлары алыначак.
2021нче елнын октябрь аенда булачак халык санын алу цифрлы технологияләр кулланып узачак. Алда торган жанисәпнен топ яналыгы - Россия халкы тарафыннан дәүләт хезмәтләренен бердәм порталында (Gosuslugi.ru) электрон исәпкә алу мөмкинлеге тудырылган. Торак биналарны карап чыкканда исәпкә алучылар махсус программа белән тәэмин ителгән планшетлардан файдаланачак. Шулай ук исәпкә алу участокларында, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнен күпфункцияле үзәкләре биналарында да исәпкә алырга мөмкин булачак.
Ботенроссия халык санын алуны Росстат - Дәүләт статистикасы федераль хезмәте

оештыра һәм координацияли. Халык санын алучыларга махсус портфель, планшет, таныклык бирелә. Алар шулай ук махсус символикалы шарф, утны кире кайтаргыч элементлы жилет белән тәэмин ителәләр.
Кинәшмә кысаларында «Россия Студентлар отрядлары» ботенроссия яшьләр ижтимагый оешмасынын региональ бүлекчәсе әгъзаларын студентлар - исәпкә алучылар сыйфатында әлеге әһәмиятле вакыйганы оештыруга жәлеп итү буенча хезмәттәшлек итү шартлары һәм мәсьәләләре каралды.
- Әйтегезче, нинди мәгълумат жыела?
- Исәпкә алучыларга гаиләләр составы, аларнын яшәү шартлары, без аралаша торган тел, гражданнарнын мәшгульлеге, аларнын белемнәре турындагы мәгълүматларны туп-лау бурычы йокләнгән. Бу мәгълүматлар дәүләт очен бик моһим – алар безнен жәмгыятьнен киләчәк үсеше очен нигез булачак.
Россиядә елдан артык яшәүчеләр 33 сорауга жа- вап бирәчәк. Әлеге сораулар ике блоктан тора. Бер блокта – кешенен үзе һәм йорт хужалыгы турында, икенчесендә – торак шартларына кагылышлы мәгълүмат.
- Асия Шамиль кызы, жанисәпнен топ кагыйдәләре турында да әйтсәгез иде?
- Сан алунын топ кагыйдәләре: регуляр рәвештә уздырылуы. Мәгълүматларнын сер итеп саклануы. Жанисәптә һәркемнен катнаша алуы (балалар очен әти-әниләре жавап бирә). Сорауларга ничек жавап бирергә икәнлекне кеше үзе хәл итү. Мәгълүматнын билгеле моментка карата жыелуы.

Мәселманнар өчен халык санын исәпкә алу - игелекле эш



Мордовиянен Атюрьево районында ике конфессия бергә дус яши – моселманнар белән христиан динендәгеләр. Моселманнар бу акциягә ничек каравы турында В.И.Ермишев Татарлар Велязьмасы авылы мулласы Исмаил хәзрәт Сюняевка морәжәгать иткән. Анын жавабы түбәндә.

Жанисәп, моселман постулатларына бернинди каршылык күрсәтми, ә киресенчә моселман һәм хокүмәт очен үткәрелә. Безнен кадерле Мохәммәд пәйгамбәргә (салләллаһу галәйһи вәсәлләм), болай дигән: Ватанга мәхәббәт – ул синен исламга ышанунын бер олеше. Жанисәптә катнашу, ул һәрбер моселманнын илахи бурычы һәм гамәле, ягъни биш вакыт намазны үтәгән күк. Шул рәвешле жәмгыять бүгенге үз халәтен күрә, аны кичәгесе белән чагыштыра, иртәгәгә юлын хәстәрли. Хәтта паспортта югалган миллилек графасын да шул жанисәп аркылы беләбез.
Россиядә жанисәп никадәрле кеше ислам динен тота икәнен дә билгели. Теге яки бу этник группаларнын яшәешен дә тогәлли. Әйтик, бүген Россиядә 11 миллион этник моселман бар: татар, башкорт, Тоньяк Кавказ халкы... Ә билгеле чыганакларда 15 млн. ислам динле этник группа бар, диләр. Ислам динле халыкнын санын исәпкә алу, гади иттереп әйткәндә, ничә мулла, ничә мәчет, ничә дини йорт кирәклеген генә белү очен дә кирәк. Шул рәвешле, халык санын алу күрсәткече зур кочкә ия: ул този дә, жимерә дә ала.
Россиядә бүген 100дән артык халык, милли торкем христиан һәм моселман цивилизациясе чигендә яши. Бу моһим: бар милләтне күз алдында, исәптә тотарга кирәк.

Сан алу – гомуммилли тупланута, социаль киеренкелекне киметүгә ярдәм итүче акция. Аны үткәрү һәм нәтижәләре белән бар кеше кызыксына. Чонки ул – ботен илнен сәяси тормышында катнашунын бердәнбер реформасы.
Мин халкыбызны татар дип, зур олы халык дип күрәм һәм үзенен татар милләтле булуы белән горурланып жанисәп соравына жавап кайтарыр дип ометләнәм.

Наилә НАСЫРОВА әзерләде